Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**“Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында” 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның дүртенче абзацында “дәүләт идарәсе” сүзләрен “башкарма хакимияте” сүзләренә алмаштырырга;

2) $1^1$ статьяда:
а) беренче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
б) икенче өлештә “районнарның, шәһәрләрнең администрацияләре” сүзләрен “җирле үзидарә органнары” сүзләренә алмаштырырга;

3) 5 статьяда:
а) беренче өлештә “район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясенә” сүзләрен “җирле үзидарә органына” сүзләренә алмаштырырга;
б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
в) өченче өлештә “район, шәһәр яисә шәһәрдәге район җирле администрациясе” сүзләрен “җирле үзидарә органы” сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяның беренче өлешендә “Республика” сүзен төшереп калдырырга, “халык депутатларының җирле Советлары” сүзләрен “җирле үзидарә органнары” сүзләренә алмаштырырга;

5) 11 статьяның икенче өлешендә “район, шәһәр һәм шәһәрдәге район җирле администрациясенең” сүзләрен “җирле үзидарә органының” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2013 елның 6 ноябре
№ 86-ТРЗ